**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НОВОИЛЬМОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Улица Ключевая, дом 15, село Новое Ильмово,
Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Чишмә урамы, 15 нче йорт, Яңа Элмәле авылы,
Чирмешән районы, ТР, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email: Nilm.Cmn2@tatar.ru


№63 12 май 2022

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 августындагы 61 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2022 елның 1 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 августындагы 61 номерлы карары белән расланагн Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә 3 бүлекнең «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-

бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемennән артып китсә, һәм алыш-биреш кылу өчен чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе В.П.Мельников